# БӨЕК ТУКАЙ

(1886-1913)

# И ТУГАН ТЕЛ, И МАТУР ТЕЛ!



- Туган тел
- И туган тел, и матур тел,
  әткәм-әнкәмнең теле!
  Дөньяда күп нәрсә белдем
  син туган тел аркылы.
- Иң элек бу тел белән әнкәм
  бишектә көйләгән,
  Аннары төннәр буе әбкәм
  хикәят сөйләгән.
- И туган тел! Һәрвакытта
  ярдәмең белән синең,
  Кечкенәдән аңлашылган
  шатлыгым, кайгым минем.
- И туган тел! Синдә булган иң
  элек кыйлган догам:
  Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
  әткәм-әнкәмне, ходам!

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ(1886-1913)



- Габдулла Тукай халкыбызның бөек шагыйре генә түгел, әдәби тәнкыйтьче, көлү остасы,журналист сәясәтче,икътисадчы һәм мөгаллим дә.
- Г.Тукай 1886 елның 26 апрелендә Арча районы  Кушлавыч авылында туа

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ – БАЛАЛАР ЯЗУЧЫСЫ



- Г.Тукай үзе исән чакта дөнья күргән 36 китабының 16 сы турыдан – туры балаларга атап чыгарылган

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕ



**Казанда Тукай һәйкәле**




**Төркия башкаласы Анкара шәһәрендә татар шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл 2011 елның 26 маенда ачылды. Ул Анкараның 2000нче еллар башында Габдулла Тукай исеме бирелгән урамында куелды.**

# ТУКАЙ МУЗЕЕ







- Менә безнең алдыбызда - 74 нче йорт. Аны 1903 елда Аппаков дигән сәүдәгәр төзеткән. Бу йорт халык телендә, шунда яшәгән кеше исеме белән бәйле рәвештә, "Шамил йорты" дип йөртелә. Йортның соңгы хуҗасы Вәлиулла Ибраһимов була. Тукай үлеменнән соң, В. Ибраһимов "Бәхет ачкычлары" исемле конфет тартмасында Тукайның фоторәсемен бастырып чыгара (Тукайның фотосурәте төшерелгән конфет тартмасы күрсәтү) 1929 нчы елда В.Ибраһимов Америкага күчеп киткәч, йорт төрле вазифалар башкара, торак йорт итеп тә файдаланыла. 1986 нчы елның 11 июнендә бу ике катлы бинада Г. Тукай музее ачыла.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ



- ***Ятим шагыйрь***

1.Кече яшьтән ятим калсаң да син,
Сөймәгәннәр кочып-иркәләп.
“Асрамага бала бирәм!”- диеп,
Йөрткәннәр бит сине җитәкләп.

2.Бирелмәгәнсең язмыш типкесенә.
Кусалар да кире кергәнсең.
Бик аз гына гомер яшәсәң дә,
Бөек әдип була белгәнсең.

3.Әкиятеңдәге геройларыңа да
Бар холкыңны бирә алгансың.
“Былтыр” кебек кыю, батыр,
Сабыр шагыйрь булгансың.

Гарипова Зөлфирә.

# ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ.

- ***Тукай шигырьләрендә төшеп калган сүзләрне язарга кирәк***



- Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и яшь ...! ("Шүрәле")
- ... килә шундый каты, шундый кызып, полный ход килгән трамвайны узып.( "Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш").
- Вә һәрберсе ..., кикерәләр дөбер-шатыр;Тамак туйгач төкер-какыр, - бөтен эч май гына, май-май! ("Сорыкортларга")
- Гали аны чирәм белән кунак итә, ... рәхмәт укый сакалын селкетә. ("Гали белән Кәҗә")

# ТУКАЙ ТУРЫНДА КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР

- **Тукай үз халкының иң сөекле шагыйре. Аның ана теле турындагы тәэсирле сүзләре бүген гимн булып яңгырый, бөтен дөньяда үз туган телен сөючеләрне, милли мәдәнияткә гашыйк кешеләрне берләштерүче фактор булып тора.**

  **Р. Миңнеханов.**

- Тукай – безнең олуг милли шагыйремез иде. Тукай- безнең иске тормышның черегән чүбе өстенә үскән матур чәчәгемез иде. Тукай- безнең мәктәп балаларымыз өчен, яшь буынмыз өчен милли каһарманымыз. Тукай- безнең киләчәктә татар әдәбияты салына торган таза бер нигеземез... .

  Г. Исхакый.

- Шәм яктысы төпкә төшми, Тукай - ул шәм: ерагайган саен, аның яктысы көчәя генә бара. Инде 100 елдан артык аның шәме яктысында җылынабыз. Ә бит ул 7 ел гына иҗат иткән! Шушы вакыт эчендә җылылыгы 700 елга җитәрлек учакка ут кабызган. Черек үпкәле, күзенә ак төшкән итеп сурәтләмәячәкләр, киләчәк буыннарда ул баһадир булып күзалланачак - монысы шиксез.


  Р. Батулла

- Бөек кешеләр нинди генә милләттән булмасыннар барлык кешегә хезмәт итәләр.Тукай сүзе һәм даны еракларга, аеруча, төрки телле өлкәләргә таралды.

  М. Кәрим.

# Г.ТУКАЙ ДУСЛАРЫ ЯНЫНДА

- Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов





# ТУКАЙ КАБЕРЕ ЯНЫНДА




- Тукай рухы яши күңелләрдә!



# ТУКАЙГА ХАТ

1.Язам сиңа сәлам хатымны.
Язам үткән еллар  аркылы.
Җиткерәсе иде рәхмәтемне,
Тукай, сиңа хатым аркылы.

2.Кечкенәдән таныш  Шүрәлең,
“Су анасы” әкиятләрең.
Хыял диңгезенә тоташтыра
Кырлайларың, урман-күлләрең.

3.Кыска гына гомер чикләрендә,
Иҗат иткәнсез сез шигырҗләр.
Шуңа да барча галимнәр,
Пушкин белән сине тиңлиләр.

4.Тукаебыз! Онытмас сине халкың.
Һәйкәлләрең тиздән  тагын  калкыр.
Әкиятләрең  тыңлап үсәр  сабыйлар,
Иҗатыңнан алар гыйлем алырлар!

Гарипова Зөлфирә.

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!